**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2022 елның 23 гыйнвары.

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелде, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 29 ноябрендәге 98-РС номерлы карары белән билгеләнде.

Комлы Ковал авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2021 елның 29 ноябрендәге 98-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2021 елның 6 декабрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2021 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Камская новь» газетасында;
3. 2021 елның 6 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 6 декабрендә 5967/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр 2021 елның 6 декабрендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2021 елның 8 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлегенең рәсми сайтында;
2. 2021 елның 8 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Камская новь» газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);
3. 2021 елның 8 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе рәисе урынбасары- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе секретаре- Прокофьева Любовь Ивановна.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2022 елның«21»гыйнварындагы Комлы Ковал авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 18 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:

1. Халык тыңлауларын үткән дип танырга;
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын, 2022 елның«21»гыйнварындагы ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре __________________________ Прокофьева Л.И.